МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.06.2024 Казан ш. № под-1150/24

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 11 мартындагы под-431/16 номерлы «Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Рәсәй Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законына, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законына, 2010 елның 01 июлендәге 821 номерлы «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» Рәсәй Федерациясе Президенты Указына, Татарстан Республикасының 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» Законына, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» Законына ярашлы рәвештә б о е р а м:

1. 11.03.2016 елның под-431/16 номерлы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» боерыгына (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 22.03.2018 ел № под-519/18, 24.10.2022 ел № под-1793/22, 11.05.2023 ел №под-967/23, 05.09.2023 ел № под-1549/23 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре, министрлык) чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнарда

билгеләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итүдә (алга таба - хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтыны җайга салу таләпләре); »;

3.1 пунктын «е» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е) дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәүгә комачаулаучы аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килүе турында хәбәр итү.»;

3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы зат тарафыннан карала, ул хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча мотивацияле нәтиҗә әзерләүне гамәлгә ашыра.»;

3.4.2 пунктында «3.1 пунктының «д» пунктчасындагы» сүзләрен «3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алыштырырга;

3.4.3 пунктның «а» пунктчасында «3.1 пунктының «д» пунктчасындагы» сүзләрен «3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алыштырырга;

3.4.3 пунктының «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, һәм «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча мотивацияле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең яки башка карарның 3.13, 3.15.1, 3.15.2, 3.18 пунктларына ярашлы рәвештә карарларның берсен кабул итү өчен тәкъдимнәр. »;

3.7 пунктында «3.1 пунктының «д» пунктчасындагы» сүзләрен «3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алыштырырга;

3.8 пунктында «3.1 пунктының «б » пунктчасындагы» сүзләрен «3.1 пунктының «б» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алыштырырга;

3.8.1 пунктының «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) әгәр әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» һәм «е» пунктчаларында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки хәбәрнамәдә дәүләт граждан хезмәткәренең яки гражданның комиссия утырышында шәхсән катнашырга нияте турында күрсәтмәләр булмаса;»;

3.15 пунктын 3.15.2 пунктчасы белән тулыландырырга:

«3.15.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтыны җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин булмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтыны җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин булмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

3.19 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, нигезләр булганда Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11 – 3.15.2, 3.17 – 3.18 пунктларында каралганнан башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итүнең

нигезләре һәм мотивлары комиссия утырышы протоколында чагылдырылырга тиеш.».

2. Министрлыкның Мәгълүмати технологияләр һәм иминлек үсеше бүлегенә (И.Н.Сарманов) әлеге боерыкны Министрлыкның рәсми сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлегендәге «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе» / «Норматив документлар» өлешендә урнаштырырга.

3. Кадрлар сәясәте бүлегенә (Г.Х.Гатауллина) әлеге боерыкны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән срокта Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвен тәэмин итәргә.

4. Бу боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Министр в.б. А.И.Поминов